СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2019 Баулы шәһәре № 233

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне
хәл итү буенча җирле үзидарә
органнары вәкаләтләрен үтәгәндә
барлыкка килә торган чыгым
йөкләмәләрен финанслашу
максатларында Баулы
муниципаль районы
бюджетыннан Баулы муниципаль
районы шәһәр һәм авыл
җирлекләре бюджетларына
субсидияләр бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Баулы муниципаль районы бюджетыннан Баулы муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашырганда Баулы муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен (алга таба – субсидияләр) финанслашу максатларында бирелә. Субсидияләр бирү шартлары, субсидияләр бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу критерийлары һәм аларны муниципаль берәмлекләр арасында бүлү Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының норматив-хокукый актлары (алга таба - район Башкарма комитеты) белән билгеләнә.

2. Субсидияләр Баулы муниципаль районы Советының «Тиешле финанс елына һәм план чорына Баулы муниципаль районы бюджеты турында»гы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре

лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче - район Башкарма комитеты.

4. Баулы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләрне бүлү Баулы муниципаль районы Советының «Тиешле финанс елына һәм план чорына Баулы муниципаль районы бюджеты турында»гы карары белән раслана.

5. Субсидияләр бирүнең максатлары һәм тәртибе район Башкарма комитеты һәм җирлек башкарма комитеты арасында төзелә торган килешүләр белән билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм аны тоту шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы;

д) субсидия бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны тормышка ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе.

7. Килешү проектын әзерләү район Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

8. Килешү проекты район Башкарма комитеты тарафыннан җирлек башкарма комитетына җибәрелә.

9. Килешү район Башкарма комитеты җитәкчесе һәм җирлек башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзалана.

10. Район Башкарма комитеты районның финанс-бюджет палатасына акча күчерү вәкаләтләрен тапшыра.

11. Авыл җирлеге башкарма комитеты субсидия алу өчен, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән вакыт эчендә, район финанс-бюджет палатасына түбәндәге документларны тапшыра:

район Башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирүгә гариза.

12. Җирлек бюджетына бирелә торган субсидия күләме, муниципаль берәмлекне сайлап алу критерийлары һәм шартлары район Башкарма комитетының норматив-хокукый актында билгеләнә.

13. Субсидияләр районның финанс-бюджет палатасы тарафыннан җирлекләр бюджетларына Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнарының килешүдә билгеләнгән срокларда җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылагн счетларына күчерелә.

14. Субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты керемenә күчерелергә тиеш.

15. Субсидияләр бирү елыннан соң килгән елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләр калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә Баулы муниципаль районы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

16. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын район закон нигезендә Башкарма комитеты һәм районның финанс-бюджет палатасы контрольдә тота.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе — Р.Х. Гатиятуллин